КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 14 октябрь г.Казань № 924

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 325 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 325 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 24 февраль, 101 нче; 2009 ел, 9 ноябрь, 776 нчы; 2010 ел, 9 апрель, 253 нче; 2010 ел, 9 июнь, 454 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1038 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 21 февраль, 125 нче; 2011 ел, 25 март, 220 нче; 2011 ел, 13 апрель, 291 нче; 2011 ел, 29 июль, 613 нче; 2011 ел, 13 август, 674 нче; 2012 ел, 8 июнь, 494 нче; 2012 ел, 30 июль, 646 нчы; 2013 ел, 9 февраль, 80 нче; 2013 ел, 14 март, 163 нче; 2013 ел, 7 октябрь, 730 нчы; 2013 ел, 30 ноябрь, 940 нчы; 2014 ел, 5 февраль, 64 нче; 2014 ел, 29 март, 201 нче; 2014 ел, 11 ноябрь, 853 нче; 2015 ел, 2 февраль, 49 нчы; 2015 ел, 3 июнь, 401 нче; 2015 ел, 20 август, 610 нчы; 2015 ел, 2 октябрь, 733 нче; 2016 ел, 26 февраль, 121 нче; 2016 ел, 25 ноябрь, 874 нче; 2017 ел, 9 февраль, 74 нче; 2017 ел, 10 июль, 468 нче; 2017 ел, 6 ноябрь, 846 нчы; 2017 ел, 30 ноябрь, 930 нчы; 2018 ел, 29 март, 185 нче; 2018 ел, 4 май, 317 нче; 2018 ел, 27 июнь, 523 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1140 нчы; 2019 ел, 16 гыйнвар, 9 нчы; 2019 ел, 4 апрель, 270 нче; 2019 ел, 29 сентябрь, 860 нчы; 2020 ел, 26 март, 220 нче; 2020 ел, 21 апрель, 311 нче, 2020 ел, 25 май, 424 нче, 2020 ел, 26 август, 744 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы (алга таба – Министрлык) хезмәткәрләренең чик санын вазыйфаи окладлар, тариф ставкалары буенча айлык хезмәт хакы фонды 6 220,2 мең сум булган 383 берәмлек күләмендә билгеләргә, шул исәптән:

130 берәмлек - Министрлыкның үзәк аппараты хезмәткәрләре вазыйфаи окладлары, тариф ставкалары буенча айлык хезмәт хакы фонды 2 968,5 мең сум тәшкил итә;

253 берәмлек - Министрлыкның территориаль идарәләре һәм Үзәк махсуслаштырылган инспекциясе хезмәткәрләре вазыйфаи окладлары, тариф ставкалары буенча айлык хезмәт хакы фонды 3 251,7 мең сум тәшкил итә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы турындагы Нигезләмәнең 3.3. пунктындагы 3.3.10 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүреш су белән тәэмин итү чыганакларын санитар саклау зоналарын билгеләү, үзгәртү һәм туктату турында карар кабул итә. Эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүреш су белән тәэмин итү чыганакларын санитар саклау зоналарын билгеләү, үзгәртү турындагы карарлар мондый зоналар чикләренең санитар кагыйдәләр чикләрендә җир кишәрлекләрен куллануны чикләүнең туры килүе турында санитар-эпидемиологик нәтиҗә булганда кабул ителә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин